УРАЗА
Ураза тотучы кешенең ике шатлыгы бар...
→ 4-5 БИТЛӘР

КЫЙССА
Һабил белән Кабил кыйссасы
→ 7 БИТ

МЕҢЪЕЛЛЫК ТАРИХ
Гарәп географлары һәм сәяхәтчеләре Болгар хакында
→ 10-11 БИТ

НӘСЫЙХӘТ
Рамазан аеннан соң безнең халәт
→ 12 БИТ

**АПРЕЛЬ, 2022**
№ 04 (321)
Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы
Рамазан, 1443

# دين و معيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

12+

# Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы мөбарәк булсын!



ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ БУЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫГЫЗ!

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 04 (321) апрель, 2022 | Рамазан, 1443

# ҖӨМҺҮРИЯТЕБЕЗДӘ ЗУР ВАКЫЙГА – ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮНЕҢ 1100 ЕЛЛЫГЫ

**Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабу итү – мөһим, җөмһүриятебезнең киләчәген үзгәртә торган зур вакыйга була. 1100 еллык тарих артта калып бара, әмма без шул вакытта утырткан агачларның бүгенге көндә дә нинди җимешләр биргәнен күреп торабыз. Әлбәттә, барыбызга да таныш булган «Болгар җыены» безне ел саен бу тарихны искә төшерергә, шул атмосферага керергә чакыра. Без дә сезгә, кадерле укучыларыбыз, 2022 елда шушы олуг вакыйгага, – Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган кайбер вакыйгаларны исегезгә төшереп үтәбез. Шулай итеп…**

### ИТИЛ ЕЛГАСЫНДА МӨСЕЛМАННАР КОРЫЛТАЕ

5 нче гыйнварда Болгарда тантаналы рәвештә Рәсәйкүләм мөселман җыены ачылган иде. Анда катнашу өчен республикалардан һәм төбәкләрдән дин кардәшләр җыелды. Форумның эшендә күренекле экспертлар, галимнәр, атаклы вәгазьчеләр эшләде. Остазлар фәнни-популяр лекцияләр, вәгазьләр, презентацияләр, мастер-класслар белән чыгыш ясады. биредә беренче тапкыр «Ибн Фадлан» документаль-нәфис фильмының киңәйтелгән трейлеры һәм «Хозур ТВ» телеканалында татар теленә тәрҗемә ителгән «Билал» мультфильмы күрсәтелде, шулай ук «Туганбатыр» милли проекты тәкъдим ителде.

### КОРЪӘННЕҢ КУЛЪЯЗМА МОСХАФЫ ЯЗЫЛА

12 нче гыйнварда, Казанның «Кол Шәриф» мәчетендә бөтен Рәсәйдән килгән мөфтиләр һәм дин әһелләренең хәер-фатихасы белән Дия нәзарәтенең яңа проектына старт бирелде – Коръәннең кулъязма мосхафын язу тантаналы рәвештә башланып китте. Күпсанлы кунаклар алдында каллиграф Изге Коръәннең беренче «Фатиха» сүрәсен язган иде. Бүгенге көндә 30нчы өлеш тә тәмам, эш алга таба дәвам итә. Проектның төп башкаручысы – Казан каллиграфы Артур Писаренко.

### ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮНЕҢ 1100 ЕЛЛЫГЫН ҮТКӘРҮ БУЕНЧА УТЫРЫШ

12 нче гыйнварда Казанда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов рәислегендә Идел буе Болгар дәүләтендә рәсми рәвештә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына әзерләнү һәм аны үткәрү буенча Республика оештыру комитетының киңәйтелгән утырышы узган иде. Утырышта Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Нәзарәтнең 1100 еллык кысаларындагы башлангычлары хакында сөйләгән иде. «Хозур» нәшрият йорты җитәкчесе Ришат Хәмидуллин Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам кабул ителүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү логотипы проектын тәкъдим иткән иде.

### МӨСЕЛМАН ЯШЬЛӘРЕНЕҢ КЫШКЫ ФОРУМЫ ҮТТЕ

Гыйнвар аенда Татарстан Диния нәзарәте Казанда һәм Болгарда мөселман яшьләренең кышкы форумын уздырды. Унөченче тапкыр оештырыла торган форумда 60 егет һәм 60 кыз катнашты. Ел саен уза торган әлеге форум яшьләргә белемнәрен ныгытырга гына түгел, берләшергә, танышырга, рухи яктан баерга һәм үзләренең социаль башлангычларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирә.

### БОЛГАРДА КОРЪӘННЕ ХӘТЕМ КЫЛА БАШЛАУГА – 2500 КӨН

2015 елның 14 июнендә Болгар шәһәрендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин башлангычы белән Коръәнне өзлексез хәтем кылу – Изге Китапны башыннан алып ахырына кадәр уку башланды. Бүгенгегә кадәр, биш вакыт намазларны укудан кала, биредә хәтем кылу бер көнгә дә тукталмады. Нәтиҗәдә, 17 нче апрельдә, татар хафизлары тарафыннан Шәһре Болгарда Коръән укыла башлауга 2500 көн тулды. Бу эштә көн саен иртәнге 9.00-дән 17.00-гә кадәр 6 хафиз катнаша һәм алар Коръәнне тулысынча 3,5-4 тәүлек эчендә укып чыгалар.

### КАЗАНДА 10 РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ ИФТАР УЗАЧАК

2022 елның 30 нчы апрелендә Татарстан мөселманнары Казанда күптән көтеп алынган мәҗлескә – 10 Республикакүләм ифтарга җыелачак. Быел ул Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы уңаеннан узачак. Республикакүләм ифтар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, «Ак барс Арена» стадионы дирекциясе һәм «Туган авылым» милли-туристик комплексы тарафыннан оештырыла.

### ПИТРӘЧТӘ МӘҮЛӘ КОЛЫЙ МИРАСЫН ӨЙРӘНҮ ҺӘМ САКЛАУ ҖЫЕНЫ УЗДЫ

1 нче апрельдә Питрәч районында XVII гасырның бөек татар шагыйре һәм дин эшлеклесе Мәүла Колыйның иҗади мирасын өйрәнүгә һәм исемен мәңгеләштерүгә багышланган чаралар узды. Рәсәйкүләм конференция эшендә күпләгән тарихчылар, әдәбият галимнәре, дин эшлеклеләре, археологлар, этнографлар, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр катнашты. Быелгы фәнни җыен Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышлап үткәрелде. Конференцияне Питрәч мөхтәсибәте теләктәшлеге белән район хакимияте оештырды.

### ҖӘМИГЪ МӘЧЕТЕНЕҢ ЭСКИЗ ПРОЕКТЫНА КОНКУРС ИГЪЛАН ИТЕЛДЕ

1 нче апрельдә, массакүләм мәгълүмат чаралары өчен узган брифингта Казан шәһәре Җәмигъ мәчете



Фото: yandex.ru

һәм тирә-юнь территориянең эскиз проектын эшләү өчен халыкара конкурс башлануы турында игълан иттеләр.

Казан шәһәре Җәмигъ мәчете комплексы төзелеше 2022 елда Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча төп чараларның федераль планына кертелгән.

## ТАТАРСТАНДА РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ «ТАТАР АЗАНЫ» БӘЙГЕСЕ ИГЪЛАН ИТЕЛДЕ

Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан «Рухи моң» иҗат берләшмәсе изге Рамазан аенда Республикакүләм «ТАТАР АЗАНЫ – 2022» бәйгесен игълан итте. Быел ул өченче тапкыр үткәреләчәк.

«Татар азаны» бәйгесенең төп максаты булып – мәчетләрдән яңгырый торган азанның сыйфатын үстерү, сәләтле азан әйтүчеләрне барлау, мәхәллә тормышын җанландыру тора. Катнашучылар барлык мәгълүматлар белән оештыручылар тарафыннан махсус эшләнгән azan.tatar сайтында таныша ала.

## БАЛТАЧТА 300-ГӘ ЯКЫН БАЛА КАТНАШЫНДА КОРЪӘН УКУ БӘЙГЕСЕ ҮТТЕ

30 нчы март көнне Балтач Үзәк мәчетендә балалар арасында районкүләм Коръән укучылар бәйгесе үткәрелде. Әлеге бәйге Балтач мөхтәсибәте мәчетләрендә ел дәвамында Коръән укырга өйрәнгән балаларның белемнәрен сынау, мөмкин кадәр күбрәк сүрәләрне яттан өйрәнүгә шартлар тудыру максатыннан оештырылды. Быелгы ярыш Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы уңаеннан зурлап үткәрелде. Әйтергә кирәк, Балтач мөхтәсибәтендә Коръән бәйгесе моннан 29 ел элек Борбаш авылында оештырыла башлый.

## «МӨХӘММӘДИЯ» МӘДРӘСӘСЕ ШӘКЕРТЛӘРЕ 1100 ЕЛЛЫКНЫ ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ БЕЛӘН КАРШЫ АЛДЫ

30 нчы март көнне, «Мөхәммәдия» мәдрәсендә Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүгә 1100 еллык һәм мәдрәсәнең нигез салынуына 140 еллык юбилейлары уңаеннан сәнгатьле итеп шигырь сөйләү бәйгесе уздырылды. Күркәм шигырь бәйрәме Изге Коръән аятьләрен укудан һәм дога кылудан башланып китте.

Бәйгедә көндезге бүлектә укучы 60-ка якын шәкерт катнашты. Шигырьләр дин, динебезнең матурлыгы, әхлак-әдәп мәсьәләләренә багышланган иде.

## ХАТЫН-КЫЗЛАР АРАСЫНДА КОРЪӘН УКУЧЫЛАР БӘЙГЕСЕ ҮТКӘРЕЛӘЧӘК

15 нче майда Ютазы районы Урыссу бистәсендә хатын-кызлар арасында «Халисә» III Рәсәйкүләм Коръән укучылар бәйгесе үткәреләчәк. Конкурс Татарстан мөфтияте, Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге казыяте, Ютазы районы хакимияте һәм Мәрданшиннар гаиләсе ярдәме белән Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышланган чаралар кысаларында оештырыла.

Бәйге мөслимәләр арасында Коръән буенча белем дәрәҗәсен күтәрү һәм Коръәнне яттан өйрәнүгә омтылышны үстерү һәм иң сәләтле Коръән укучыларны билгеләү максатыннан уздырыла.

Мәгълүмат
**dumrt.ru** сайтыннан алынды

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 04 (321) апрель, 2022 | Рамазан, 1443

# УРАЗА ТОТУЧЫ КЕШЕНЕҢ ИКЕ ШАТЛЫГЫ БАР...




Фото: yandex.ru

**Рамазан аен кадерле кунак белән чагыштыру бигрәк тә дөрес сүзләр икәнен, мөбарәк аебызның соңгы көннәренә килеп җиткәч, тагын да ныграк тоябыз. Ул, чыннан да, ай күрде, кояш алды, дип чагыштырганча, әле генә сагындырып килеп җитә дә, сизелмичә, үтеп тә китә. Әмма үзенең бәрәкәте, тәме, кадерле сәхәрләре, ифтарлары, күңелгә рәхәтлек бирә торган күркәм тәравих намазлары белән киләсе елга кадәр күңелебездә саклана. Һәрхәлдә, шулай булсын өчен, без үзебездән күп тырышлык куярга, Рамазан аен билгеле бер вакытка гына килгән кадерле кунак итеп кабул итәргә тиешбез. Пәйгамбәребез аның бөеклеге, мәртәбәсе, күркәмлеге, ураза тотуның фазыйләте хакында бик күп хәдис-шәрифләр әйтеп калдырган. Аларны карап үтик.**

Раббыбыз болай дип әйтә:

*«Ий иман китерүчеләр! Сездән алда килеп киткәннәргә [фарыз булып] язылган кебек, сезгә дә [Рамазан аендагы] ураза [фарыз буларак] язылды. Бәлки, [ачлык ярдәме белән гөнаһлардан сакланып] тәкъвалык ияләреннән булырсыз!».*

*«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183*

**Рамазан аена кагылышлы хәдис-шәрифләр:**

### РАМАЗАН – РӘХМӘТ АЕ

Пәйгамбәребез: «Рамазан аеның беренче ун көне – рәхмәт, икенче ун көне – мәгъфирәт, өченче ун көне – җәһәннәмнән котылу. Берәү бу айда малын корбан итсә, Аллаһы аны уттан саклар», – дигән (имам Әл-Бәйһакый).

*Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Рамазан ае кергәч, җәннәт ишекләре ачыла, җәһәннәм ишекләре ябыла, шәйтаннар баглана», – дигән сүзләрен тапшырган (имамнар Әл-Мөслим, Әл-Бохари).*

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәрнәрсәнең зәкяте, ягъни пакьләүчесе була. Тәннең зәкяте – ураза», – дип әйткән (имам Ибне Мәҗе).

Пәйгамбәребезнең: «Ураза тотучының ике шатлыгы бар: берсе – авыз ачкан вакытта, ә икенчесе – гөнаһыбыз гафу ителгән хәлдә, Кыямәт көнендә Аллаһы белән очрашканда», – дип әйтелгән күркәм хәдисе бар (имамнар Әл-Бохари, Әл-Мөслим).

Пәйгамбәребез бер кодси хәдистә болай дигән: «Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә: «Адәм баласы кылган һәр гамәл үзе өчен, уразадан кала, чөнки ураза Минеке һәм әҗерен дә Үзем бирермен» (имамнар Әл-Бохари һәм Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

### РАМАЗАНДА БИРЕЛГӘН 5 НИГЪМӘТ

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең болай дип әйткәне билгеле: «Рамазанда минем өммәтемә биш әйбер бирелде. Башка өммәтләргә ул бирелмәде»:

1) Ураза тотучының авызыннан чыккан ис, миск (ислемай) исенә караганда Аллаһыга күпкә күркәмрәк;
2) авыз ачканчы фәрештәләр уразалы кешегә истигъфар укыр;
3) Рамазанда шәйтаннар баглаҥыр һәм башка вакытта кылган гамәлләрен кыла алмас;
4) ураза тоткан кеше өчен һәр көнне Аллаһы Тәгалә җәннәтне бизәп торыр;
5) Рамазанның соңгы төнендә Аллаһы Тәгалә тулысынча ул кешене гафу итәр.

Шунда сәхабәләр: «Йә, Расүлуллаһ, ул Кадер кичәсеме?» – дип сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм җавап итеп: «Юк, һәр кеше берәр эшен тәмамласа, ахырда хакын алыр», – дигән (имам Әхмәд).

## УРАЗА ТОТУНЫҢ ФАЗЫЙЛӘТЕ

Расүлебез: «Әгәр кешеләр Рамазан аеның үз эченә күпме нигъмәтләр алганын белсә, алар ел әйләнәсе Рамазан ае булуын теләр иде», – дигән (имамнар Әл-Бәйһакый, Ибне Хөзәймә).

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителгәнчә, бер хәдистә Расүлуллаһ: «Ураза тотыгыз, сәламәт булыгыз», – дип әмер иткән.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән тапшырылган хәдистә Пәйгамбәребез болай дип әйткән: «Сәфәрдә булу сәбәбе һәм хасталыгы булмаган кеше, Рамазан аенда бер генә көн уразасын калдырса да, гомер буе ураза тоткан очракта да аны түләп бетерә алмас» (имамнар Әбү Давыд, Әт-Тирмизи).

*Пәйгамбәребез: «Ай буе Рамазан аенда ураза тотып, аңа 6 көн шәүвәл ае уразасын өстәгән кеше ел әйләнәсе ураза тоткан савабына ирешер», – дигән (имамнар Әл-Мөслим, Әт-Табәрани).*

## АШАУ-ЭЧҮГӘ КАГЫЛЫШЛЫ ТӘРТИП

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребезнең: «Таң алдыннан сәхәр ашагыз, хакыйкатьтә, сәхәр ашауда бәрәкәт бар», – дигән сүзләрен риваять иткән (имамнар Әл-Бохари, Әл-Мөслим, Әт-Тирмизи).

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Бер кеше ураза тотканда онытылып китеп ашаса-эчсә, уразасын өзмичә төгәлләсен, чөнки аны Аллаһы Тәгалә ашаткан һәм эчерткән», – дигәнен риваять иткән (имамнар Әл-Бохари, Әл-Мөслим).

Сәлман бине Әмир радыяллаһу ганһе тапшырган бер хәдистә Расүлуллаһ болай дип әйткән: «Берегез ураза тоткач, хөрмә белән авызын ачсын, хөрмә тапмаса, су эчеп ифтар кылсын, чөнки су – пакьләүче (сусауны баса һәм ашказанын юа)» (имамнар Әт-Тирмизи, Ән-Нәсаи, Ибне Мәҗе, Әбү Давыд, Әхмәд бине Хәнбәл).

Әбү Сәгыйд Әл-Ходри радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Сәхәр ашау бәрәкәтле, аны ашамыйча калмагыз. Һич булмаса, арагыздан берегез бер йотым су эчсен, чөнки Аллаһы Тәгалә һәм фәрештәләр сәхәр ашаганнарга саләт әйтә (муллык һәм нур яудырырлар)» (имам Әхмәд бине Хәнбәл).

## УРАЗАЛЫ КЕШЕ НИДӘН ТЫЕЛЫРГА ТИЕШ?

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителгән бер хәдистә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Ялган сөйләүдән һәм ялган белән гамәл кылудан туктамаган кешенең, ураза totам дип, ашау-эчүеннән калуына Аллаһы мохтаҗ түгел» (имам Әл-Бохари).

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителгән бер хәдистә Расүлуллаһ болай дип әйткән: «Ураза – ашау белән эчүдән генә өзелеп тору түгел ул. Ураза кирәкмәгән сүзләрдән һәм гамәлләрдән, җенси теләкләрне кузгата торган сүзләр һәм гамәлләрдән тыелуны да белдерә. Әгәр бер кеше сине сүгә яки сиңа каршы белмичә хәрәкәт итә башласа, син: «Мин ураза тотам (синең сүзләреңне ишетмәм)», – дип әйт» (имам Әл-Хәким).

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе тапшырган бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөньяда никадәр ураза тотучы бар, тик аларның уразалары (харамнан сакланмаулары сәбәпле) бары тик ач торудан гыйбарәт. Дөньяда төннәрен торып никадәр намаз укучы бар, тик аларның кыямнары бары тик йокысызлык булып кына кала», – дип әйткән (имам Әл-Хәким, «Мүстәдрак», 1/431).

## УРАЗА ТОТУЧЫНЫҢ КЫЯМӘТТӘГЕ ХАЛӘТЕ

«Кеше Аллаһы юлында бер генә көн ураза тотса да, Аллаһы аның йөзен (гәүдәсен) җитмеш еллык арага җәһәннәм утыннан ерагайтыр» (имамнар Әл-Бохари, Әл-Мөслим).

Сәһел радыяллаһу ганһедән: «Хакыйкатьтә, җәннәттә «Әр-Раййән» дигән капкалар бар һәм Кыямәт көнендә аның аша бары тик ураза тоткан кешеләр генә керәчәк. «Ураза тоткан кешеләр кая?» – дип сорагач, алар уяначаклар һәм бу капкага алардан башка беркем дә кермәячәк. Алар җәннәткә кергәч, капкалар ябылыр, һәм алар аша бүтән беркем дә кермәс» (имамнар Әл-Бохари, Әл-Мөслим).

«Ураза һәм Коръән Кыямәт көнендә кол өчен шәфәгатьче булырлар. Ураза: «Ий, Аллаһы, мин аңа ашарга һәм эчәргә бирмәдем, миңа шәфәгать итәргә рөхсәт бир», – дип әйтер. Коръән: «Ий, Аллаһы, мин аңа төнлә йокларга бирмәдем, миңа шәфәгать итәргә рөхсәт бир», – дип әйтер». Һәм алар аның өчен шәфәгать кылыр» (имам Әхмәд бине Хәнбәл).

Әбү Мәлик Әл-Әшгари риваять иткән бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Чыннан да, җәннәттә шундый бер йорт бар: эченнән – тышы, тышынан эче күренә. Аллаһы Тәгалә аны йомшак сөйләшкән, кешеләрне ризыкландырган, даими ураза тоткан һәм башка кешеләр йоклаганда төнлә гыйбадәт кылганнар өчен әзерләгән» (имамнар Әхмәд бине Хәнбәл, Әт-Тирмизи, Ибне Хиббән, Бәйһакый).

## УРАЗА ТОТУЧЫНЫҢ ДОГАСЫ КАБУЛ КЫЛЫНА, ГӨНАҺЫ КИЧЕРЕЛӘ

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителгән бер хәдистә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Өч төрле кешенең догасы, һичшиксез, кабул ителә: ураза тотучының догасы, юлчы кешенең догасы һәм мәзлүмнең (хаксызга җәберләнгән, рәнҗетелгән) кешенең догасы» (имам Әл-Бәйһакый).

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребезнең әлеге сүзләрен риваять иткән: «Ихлас күңел белән ышанып, һәм савабын бары тик Аллаһыдан гына өмет итеп Рамазан ае уразасын тоткан һәркемнең кылган гөнаһлары ярлыканыр» (имамнар Әл-Бохари, Әл-Мөслим, Әбү Давыд).

Ибне Гамр радыяллаһу ганһе тапшырган бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ураза тотучы кешенең ифтар вакытында тәгаен кабул ителә торган бер догасы бар», – дип әйткән (Гали Әл-Мүттәки, «Кәнзүл Үммәл», 8/448, №23592).

Сәхифәне **Айсылу Юлдашева** әзерләде

# РАМАЗАН – КОРЪӘН АЕ

**Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе: «Дөреслектә, бу калебләр – ул савыт, шулай булгач, аларны Коръән белән тутырыгыз һәм башка нәрсә белән тутырмагыз», – дигән.**

Коръән уку Аллаһыны зикер итүнең иң хәерле юлы булып санала. Коръән укыганда тәҗвид кагыйдәләрен, тиешле булган әдәп һәм әхлак тәртипләрен үтәү кирәк. Изге Китабыбызны һәрдаим: көнен, төнен, кичен, иртәләрен укып торсак та, артык булмас. Шулай ук Аллаһы сүзләрен кайда гына булсак та – өйдә дә, сәфәрдә дә укырга тиешбез. Коръән уку, аны өйрәнү һәм, боларга өстәп, Коръәнне башкаларга өйрәтү фазыйләтле гамәл. Госман бине Гаффан радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Сезнең иң хәерлегез – Коръәнне өйрәнүче һәм аны башкаларга өйрәтүче», – дип әйткәнен риваять иткән (имам Әл-Бохари).

Сәхабәләребез, галимнәребез һәм имамнарыбыз Коръәнне укып чыгу вакытларын үзләре билгеләп куя торган булган. Кайберләре Коръәнне бер төндә укып чыкса, Изге Китапны намаздагы бер рәкәгать дәвамында укып чыгучылар да булган. Боларны истә тотып, без дә үзебезгә Аллаһы Китабын укуда билгеле бер план куярга тиеш. Мәсәлән, Рамазан аенда Коръәнне тулысынча укып чыгу, ягъни һәр көнне бер җөз укырга вакыт табу яхшы булыр. Әлбәттә, һәр кеше өчен бу план төрле була. Берәүләр өчен һәр көнне тулы җөз укып чыгу кыен, алар аның яртысын яки Коръәннең берничә битен генә укый алырга мөмкин. Әмма шуны аңларга кирәк: бу гамәлләр аз булса да, дәвамлы булырга тиеш. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы каршында иң сөекле гамәл, кечкенә генә булса да дәвамлы булганы», – дигән (имамнар Әл-Бохари, Әл-Мөслим).

Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһе: «Коръән югалганчы, аны еш укыгыз», – дип әйткән. Аннан: «Ә ул безнең калебләрдә һәм язылган төргәкләребездә булган килеш ничек югала ала?» – дип сораганнар. Ул: «Бер төн эчендә ул сезнең калебләрегездән алыныр һәм язылган төргәкләрегездән сөртелер», – дигән һәм әлеге аятьне укыган:

*«Әгәр теләгән булсак, сиңа вәхи иткән нәрсәне [тулысы белән] юк итәр идек».*

*«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:86*

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһедән тапшырыла, Пәйгамбәребез: «Әгәр кеше төннең башында Коръән укып тәмамласа, фәрештәләр иртәнге вакытка кадәр аңа изге теләк теләп торыр. Әгәр ул төннең азагында Коръән укып тәмамласа, фәрештәләр кичкә кадәр аңа изге теләк теләп торыр», – дигән (имам Әд-Дәрими).

Коръәнне тәҗвид белән укудан тыш, аны укыганда ихлас булырга тиешлегебезне онытмыйк. Коръәнне Аллаһы ризалыгы өчен генә укыйбыз һәм бу вакытта үзебезнең Аллаһы Тәгаләнең әңгәмәдәше икәнен истә тотарга тиешбез.

Пәйгамбәребез болай дип әйткән: «Кешенең Коръәнне яттан (китапсыз) укуы – ул мең әҗер-савап, ә ятлаганын китаптан укыганда әҗер-савап ике меңгә кадәр арта» (имамнар Әт-Табәрани, Бәйһакый). Димәк, яттан белгән Коръәнне кулга тотып уку күпкә фазыйләтлерәк, чөнки бу вакытта без Аллаһының сүзләренә тагы да зуррак игътибар күрсәтәбез, аятьләр турында фикерлибез. Әлбәттә, яттан уку да бик фазыйләтле гамәл. Гомумән, Коръәнне яттан өйрәнү олуг нигъмәт. Коръән уку турында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Коръәнне укыгыз, чөнки Кыямәт көнендә ул укучыларына шәфәгатьче булыр» (имам Әл-Мөслим).

Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе Расүлебезнең болай дип әйткәнен тапшырган: «Аллаһы һәм Аның Расүле аны яратуына куанган кеше мосхаф буенча Коръән укысын». Рамазан аенда Коръәни Кәрим белән мөнәсәбәтләребезне тагы да яхшыртырга тиешбез, чөнки бу – Галәмнәрне Яратучының сүзләре. Коръән – ул безнең өчен кулланма, җитәкчелек. Раббыбыз болай дип әйтә:

*«Ул – [пәйгамбәрләр галәйһимуссәлам хәбәр иткән] үзендә бер шик тә булмаган, мөттәкыйләр [Аллаһы рәхмәтен югалтудан куркучы тәкъвалар] өчен юл күрсәтә торган Китап».*

*«Әл-Бәкара / Сыер», 2:2*

Коръәни Кәримдә ике дөнья бәхете бар. Аны укып, без күңелләребезгә тынычлык табабыз, һидаятькә ирешәбез, әҗер-савапларга ия булабыз һәм ихлас йөрәктән, Раббыбыз ризалыгы өчен дип кенә укыган вакытта Аллаһының рәхмәте белән, Кыямәт көнендә дәрәҗәләргә ия булырбыз. Коръән белән мөнәсәбәтләребез ныграк булган саен, Раббыбыз белән мөнәсәбәтләребез дә ныграк булыр, ихласлыгыбыз артыр. Шуңа күрә Коръән укыганда ихлас булуыбыз, аны Аллаһы ризалыгы өчен генә укуыбыз мөһим. Әбү Сәгъд Әл-Ходри Пәйгамбәребезнең әлеге сүзләрен тапшырган: «Коръәнне өйрәнегез һәм, аның аркылы кешеләр дөньялыктагы нәрсәләрне сорый башлаганчы, Аллаһыдан җәннәт сорагыз. Дөреслектә, Коръәнне өч кеше өйрәнә: аның белән мактанучы кеше, аның аркылы ризыкланучы кеше һәм аны Аллаһы ризалыгы өчен укучы кеше».

Коръән укыганда безнең беренчел максат – Аллаһы сүзләрен һидаятькә ирештерә торган мөһим төшенчә итеп кабул итү. Аны укып кына калмыйча, аның белән гамәл кылырга, аның бөеклеген танырга кирәк. Раббыбыз Коръән белән вәгазьләнеп, аның нәсыйхәтләрен кабул итүчене акыл ияләре дип атый:

*«Акыл ияләреннән башкалар [Коръәни Кәримдәге үгетләрне] искә алмас».*

*«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:7*

Ә инде Коръәни Кәримне инкяр итеп, аннан йөз чөерүчеләр хакында Раббыбыз болай дип әйтә:

*«Кем дә кем [Китапны үзгәртеп яки хөкемнәрен кире кагып] аны инкяр итсә, шулар – [үзләрен матди һәм рухи зарарга дучар итеп] югалтучылар».*

*«Әл-Бәкара / Сыер», 2:121*

Раббыбыз укыган Коръәннәребез бәрәкәтендә Үзенең киң рәхмәте белән ике дөнья бәхетенә ирешүләребезне насыйп итсә иде.

**Тимергали хәзрәт Юлдашев,**
ТР МДНнең Дәгъват бүлеге белгече,
«Саләх» мәчете имам-хатыйбы

МӨФТИ КАМИЛ ХӘЗРӘТ СӘМИГУЛЛИННЫҢ МӘКАЛӘЛӘР ЦИКЛЫ

# «ПӘЙГАМБӘРЛӘР КЫЙССАСЫ»

ДИП АТАЛГАН ЯЗМАЛАР СЕРИЯСЕ


Фото: dumrt.ru

#ҺАБИЛ БЕЛӘН КАБИЛ КЫЙССАСЫ

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

Кабил һәм Һабил корбанга дигән мөлкәтләрен алып, аларны тау битенә өеп куйганнар. Шул мизгелдә күктән ут төшеп, Һабилнең корбанын йотып куйган, ә Кабилнең корбаны кагылмаган булып кала. Шуннан инде Һабилнең Аллаһы Тәгалә ризалыгына ирешүе, ә Кабилнең хак булмавы ачыклана. Коръәни Кәримдә бу турыда болай дип әйтелә:

*«Аларга Адәмнең [Һабил белән Кабил исемле] ике улының хәбәрен хак [бер бәян] белән укы. Менә ул икәү берәр корбан тәкъдим иттеләр; аларның берсеннән [бу корбаны] кабул ителде, икенчесеннән исә кабул ителмәде. Ул [корбаны кабул ителмәгән Кабил Һабилгә]: «Мин сине, һичшиксез, үтерәчәкмен», – диде. Ул исә әйтте: «Аллаһы тәкъвалык ияләреннән генә [корбаннарын] кабул итә».*

*«Әл-Маидә / Табын», 5:27*

Кабилне көнчелек һәм нәфрәт томалап алган һәм ул әтисен гаепли башлаган:

– Син Һабилгә дога укыдың, шуңа да аның корбаны кабул булды, әгәр син аңа дога укымасаң, аның корбаны түгел, ә минем корбан кабул ителер иде.

Аңа җавап итеп Адәм галәйһиссәлам болай дип әйткән:

– Юк, улым. Һабил корбанга үз мөлкәтеннән иң яхшысын сайлап алды, ә син булганыңның иң начарын Раббың ризалыгы өчен корбан итеп китердең. Аллаһы тәкъвалыларның корбанын кабул итә.

### ҖИРДӘГЕ БЕРЕНЧЕ ҖИНАЯТЬ

Әтисенең үгет-нәсыйхәтләре Кабилне тынычландырмаган, ул шайтан коткысына бирелгән. «Һабилне һәлак ит тә, игезәк кыз туганыңа өйлән» дигән вәсвәсә аның башын әйләндергән. Һабил исә үз туганыннан яманлык килер дип уйламаган: көтү көткәндә ул малларын иркенгә җибәргән дә, үзе бер агач күләгәсенә ял итәргә яткан. Яткан хәлендә үзенә текәлеп торган бер карашны тойган. Бу явызлык һәм дошманлыктан янып торган Кабил булган. Зиһене томаланган, шайтан вәсвәсәсенә бирелгән Кабил туганына болай дип әйткән:

– Синең корбаның кабул булды, ә минеке – юк. Хәзер миңа кешеләр арасында ничек яшәргә? Мин аларның күзләренә дә карый алмыйм! Мин сине һәлак итәргә мәҗбүрмен, шул чакта син минем игезәк туганыма өйләнә алмаячаксың.

Һабил Раббысына тәвәккәл кылып, тулысы белән язмышын Аңа тапшырган һәм бертуганына каршы бер гамәл дә кылмаган. Ул болай дип җавап биргән:

*«Әгәр син мине һәлак итергә дип кулыңны сузсаң да, мин сине һәлак итәргә дип кулымны сузмам. Чөнки, һичшиксез, мин галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыдан куркамын».*

*«Әл-Маидә / Табын», 5:28*

Бу сүзләрдән соң Кабилнең тагын да ачуы арткан, ул тыныч кына торып китәргә җыенган Һабилнең башына таш белән сугып аны һәлак иткән. Әнә шул рәвешле кешелек һәм Җир тарихында беренче тапкыр җинаять кылынган.

*«Нәфесе аны кардәшен һәлак итергә [бизәп күрсәтеп] этәрде, һәм ул аны үтерде, һәм ул [динен дә, дөньясын да] югалтучылардан булды».*

*«Әл-Маидә / Табын», 5:30*

Хәдисләрнең берсендә Аллаһының Расүле: «Гаепсезгә һәлак ителгән кеше канының бер өлеше Адәмнең беренче улына да төшә, чөнки ул кеше һәлак итүчеләрнең беренчесе булды», – дигән.

### КАБИЛ КАРГАДАН КЕШЕ ҖИРЛӘРГӘ ӨЙРӘНӘ

Кабил шәйтан коткысына бирелеп, үз туганын һәлак иткән. Соңыннан, акылына килеп, бик нык үкенгән. Коръәндә бу турыда болай дип әйтелә:

*«Шуннан [Кабил Һабилнең мәетен нишләтергә белмичә аптырап йөргән чакта] кардәшенең гәүдәсен ничек каплауны күрсәтер өчен, Аллаһы аңа җирне казып торган бер карга җибәрде. Ул [тере карганың үле карганы ничек күмгәнен күргәч]: «Ни үкенеч миңа! Мин шушы карга кебек тә була алмыйм һәм кардәшемнең гәүдәсен дә каплый алмыйммыни?» – диде. Һәм ул [бик озак кардәшенең үле гәүдәсен аркасында йөрткәне өчен] үкенгәннәрдән булды».*

*«Әл-Маидә / Табын», 5:31*

Озак вакыт үтеп тә, балалары кайтмагач, Адәм галәйһиссәлам улларын эзләргә чыккан. Әтисенең килгәнен күреп, Кабил куркып качкан.

Як-ягына карагач, Адәм галәйһиссәлам канга баткан ташны күргән һәм монда ни булганын аңлаган, кайгысыннан һәм әрнүеннән елаган.

Моны эшләп Кабил зур гөнаһ кылучы була. Шул көннән, бу яман эш кабатланган саен, гөнаһның бер өлеше аңа бара. Хәдистә болай дип әйтелә: «Кем Исламда нинди дә булса яхшы гадәткә нигез салса, моның өчен дә һәм аннан соң бу гадәтне эшләгәннәрнең дә савабын алыр. Гәрчә ул кешеләрнең саваплары һич тә кимемәс. Ә кем Исламда яман гадәт башлап җибәрсә, моның өчен ул бу эшнең гөнаһын да һәм аннан соң бу гамәлне кылган кешеләрнең гөнаһын да алыр, гәрчә моннан ул кешеләрнең гөнаһы һич кенә дә кимемәс».

# 1100 ЕЛЛЫККА «ТУГАН БАТЫР ЛЕГЕНДАЛАРЫ» КИТАБЫ ӘЗЕРЛӘНӘ

**14 нче апрельдә Татарстан мөфтияте Казанда журналистлар өчен зур традицион ифтар уздырды. Ел саен Рамазан аенда авыз ачу мәҗлесе форматында үтә торган мәҗлестә республикабыз мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм федераль, республика, шәһәр массакүләм мәгълүмат чараларында хезмәт куючы, матбугат хезмәтләрендә эшләүче алтмыштан артык каләм әһеле җыелды.**

Әлеге чарада катнашучы кунаклар арасында ТР Президенты матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Галимова, «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе (ТНВ) генераль директоры Илшат Әминов, «Татмедиа» АҖ генераль директоры Шамил Садыйков, «Татмедиа» АҖ генераль директоры урынбасары, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы баш мөхәррире Ринат Билалов һәм башкалар бар иде. Быел ифтар «Туган авылым» милли-туристлык комплексында әлеге оешма җитәкчеләренең берсе, Нәзарәт белән актив хезмәттәшлек итүче Радик Абдрахманов катнашында, аның кунакчыллык күрсәтүе белән үтте. Ифтарны бирелә үткәрүнең төп сәбәпләренең берсе – мәҗлескә җыелучыларга, авыз ачу вакыты җиткәнче, «Туган батыр» проектын тәкъдим итү белән бәйле иде. Шуңа да кичәдә тагын бер мөхтәрәм кунак булып «Туган батыр» әкият китабын язучы, танылган татар язучысы Зөлфәт Хәким катнашты.

Кичә Коръән аятьләре уку һәм Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның сәламләү сүзләре белән башланып китте. Ул кунакларга мәгълүматны тапшыру һәм аның дөреслеге принциплары өчен җаваплылык тоту турында вәгазь белән мөрәҗәгать итте, Пәйгамбәребез хәдисләрен тапшыру кагыйдәләре һәм чылбыры мисалында эшчәнлекләре турыдан-туры мәгълүмат тапшыру белән бәйле журналистларга үгет-нәсыйхәтләрен бирде. Камил хәзрәт Коръәннең әлеге аятен китерде:

*«Ий иман китерүчеләр! Әгәр [гөнаһтан сакланмаган, шуңа ялган сөйләмәячәгенә ышаныч булмаган] фасикъ бер кеше сезгә [мөһим] хәбәр китерсә, [аның асылын] тикшереп белегез, югыйсә [гаепсез] кешеләргә белмичә, зыян китерерсез дә, шуннан [гаепсез булулары ачыкланганнан] соң [аларга] кылган нәрсәгез аркасында үкенерсез».*

*«Әл-Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:6*

Камил хәзрәт Сәмигуллин, хәдисләргә таянып, мәгълүмат кабул ителү шартларын санады. Беренчедән, мәгълүмат өзлексез рәвештә тапшырылырга, икенчедән, мәгълүматны тапшыручы кеше гадел булырга, өченчедән, мәгълүмат бирүченең хәтере яхшы булырга, дүртенчедән, мәгълүмат яшерен кимчелекләргә ия булмаска тиеш.

Алга таба очрашу татар батыры образын торгызу буенча көтеп алынган проектларның берсе – «Туган Батыр»ны тәкъдим итү белән дәвам итте. Проект танылган мөселман меценаты Радик Абдрахманов һәм Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның уртак башлангычы булып тора.

«Туган Батыр» – балалар һәм яшьләр арасында татар батыры образын торгызу һәм популярлаштыру буенча чараларны гамәлгә ашыручы бренд. Бу юнәлештә беренче адым – образның концепциясен һәм аның брендын эшләү булды. Татар батырын сәнгать әсәрләрендә күрсәтү өчен, тарих, халык авыз иҗаты, әдәбият, бренд тудыру буенча белгечләр җәлеп ителде. Концепция милли геройга хас иң кыйммәтле сыйфатлар чагылыш тапкан татар мәкальләренә, әкиятләренә һәм бәетләренә үткәрелгән контент-анализ нәтиҗәләре буенча булдырылган.

Чираттагы эш этабы образны яңа сюжетлы блокбастерларда гәүдәләндерү булачак: «Туган Батыр» әкият китабында, аудиокитапта, компьютер уенында, мультфильмда, комиксларда, сувенир продукциядә һәм квест-шоуда.

Хәзерге вакытта Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү буенча тантаналы чараларга 4 телдә «Туган Батыр легендалары» дип исемләнгән әкият китабы басмасы әзерләнә. Китап ТР инвестицион үсеш Агентлыгы ярдәме белән бастырыла һәм Халыкара «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit-2022» икътисади саммитта тәкъдим ителәчәк.

Әлеге басмада легенданың башы сурәтләнә, ул – Туган Батыр турында күп серияле әкиятнең беренче өлеше. Әсәр танылган татар язучысы, драматург Зөлфәт Хәким тарафыннан язылган. Сюжетта Туган Батырның яулаган үрләре, шул исәптән аның тылсымлы сәяхәтләре, аның кардәшләре, дуслары, дошманнары белән мөнәсәбәтләре, шулай ук аның гаиләгә, Ватанга һәм... кызга булган зур һәм ихлас мәхәббәте турында сөйли. Көтелмәгән борылышлар, юмор һәм маҗаралар белән үрелеп барган сюжет төрле яшьтәге балалар һәм төрле телләрне белүчеләр өчен аңлаешлы һәм кызыклы булачак: китап татар телендә язылган һәм рус, инглиз һәм гарәп телләренә тәрҗемә ителгән. Күркәм легенда чын заманча блокбастер булырга һәм балаларда Туган батырга охшарга тырышу, үз халкыңның лаеклы улы булу теләген уятырга сәләтле.

Мәҗлеснең рәсми өлеше Татарстан мөфтиенең тантаналы рәвештә Рәхмәт хатлары тапшыруы белән тәмамланды. Рәхмәт хатлары белән түбәндәгеләр билгеләп үтелде: ТР Президенты матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Галимова, «Тәртип» радиосы баш мөхәррире Ризәлә Исмәгыйлева, «Хозур ТВ» телеканалы баш мөхәррире Исмәгыйль Гыйндуллин, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясенең (ТНВ) «7 дней» тапшыруы журналисты Илзира Юзаева һәм «Реальное время» интернет-газетасы корреспонденты Рәдиф Кашапов.

Кояш баю белән, танылган татар телевидениесе алып баручысы Илдар Кыямов азан әйтте, ә кунаклар, мөфти Камил хәзрәт артына басып, ахшам намазы укыганнан соң, авыз ачты. Кичә дустанә аралашу белән дәвам итте.

**dumrt.ru** сайтыннан



Фото: yandex.ru

# Потларны кем җимерде?

*(Дәвамы алдагы санда)*

Бәбил дәүләтенең Нәмруд исемле хөкемдары бик тә гаделсез һәм явыз кеше була. Кешеләр аннан бик нык курыкканга күрә, Ибраһим галәйһиссәламнең бер илаһлыкка чакыруыннан да баш тарталар. Берьюлы Ибраһим галәйһиссәлам Нәмруд патша янына килә дә, аны Аллаһыга иман китерүгә өнди башлый. Әмма ул шул дәрәҗәдә адашкан кеше була ки, хәтта үзен илаһ дип атый. Ул: «Бу дәүләтнең илаһы мин», – дип әйтеп, шундый зур гөнаһка керүдән дә курыкмый. Ибраһим галәйһиссәлам аңа Аллаһының Бер булуы хакында күпме генә дәлилләр китерсә дә, тәкәббер патша үз сүзеннән кайтмый.

Бәбил дәүләтендә потлар саклана торган гыйбадәтханә була. Кешеләр анда килеп, шул потларга ялвара, аларга бүләкләр калдыра торган иде. Бер көнне сыннарга табынучы бу кешеләр барысы бергә ярминкәгә киткәндә, Ибраһим галәйһиссәлам гыйбадәтханәгә кереп, потларның барысын да ватып чыга һәм соңыннан, балтасын иң олуг саналган потның муенына элеп, чыгып китә. Күпмедер вакыт үткәннән соң кешеләр кайтып бу хәлләрне күрәләр, аларның бик нык ачулары килә. Алар бу хәлләрне кылуда бер генә кешедән шикләнәләр. Ул Ибраһим галәйһиссәлам була, чөнки алар аның потларга табынмавын һәм бер илаһлыкка чакыруын белә. Бу кешеләр ачулары килеп, Ибраһим галәйһиссәламне: «Безнең потларны син җимердеңме?!» – дип гаепли башлыйлар. Ә Ибраһим галәйһиссәлам югалып калмый: «Муенында балта эленеп торган поттан сорагыз, бәлки ул беләдер», – ди. Шунда берсе: «Ибраһим, бездән көлмә! Сиңа аның тере түгел икәнлеге билгеле бит. Ул бит күрә дә, сөйләшә дә алмый. Каян белсен ул?!» – дип әйтә. Ул шулай дип әйтеп, үзләренең адашуда икәнлеген үз теле белән әйтеп бирә. Моңа җавап итеп, Ибраһим галәйһиссәлам: «Нигә алайса сезне күрми, сезнең белән сөйләшә алмый һәм сезне якларга сәләтле булмаган бу сыннарга табынасыз? Бер Аллаһыга иман китерегез», – дип әйтә.

Бу сүзләр анда булучыларга бик нык тәэсир итә, алар фикер йөртә башлый. Бу хәлләр хакында бөтен кешегә хәбәр килеп җитә. Кайберәүләр потларга табынудан баш тартып, иман китерә. Әлбәттә, бу вакыйгалар Нәмруд патшаның бик нык ачуын китерә һәм ул Ибраһимнан котылмыйча моны башкача хәл итеп булмаганлыгын аңлый. Явыз хаким пәйгамбәргә карата зур золым кылырга, аны юк итәргә җыена.

*Дәвамы киләсе санда, нәни дустым!*

Сәхифәне **Айсылу ЮЛДАШЕВА** әзерләде

«Хозур» нәшрият йорты
**«Без – татарлар»**
**бушлай онлайн татар теле курсларын**
тәкъдим итә
Татар телен beztatarlar.ru сайты һәм iOS һәм Android платформаларындагы кушымталар аша онлайн өйрәнә аласыз
Google Play App Store



# ГАРӘП ГЕОГРАФЛАРЫ ҺӘМ СӘЯХӘТЧЕЛӘРЕ БОЛГАР ХАКЫНДА

**Кызганычка, Болгар җирләре һәм дәүләте хакында безгә аз мәгълүмат килеп ирешкән. Болгар дәүләте хакында иң тәфсилле тасвирлама калдыручы кеше – ул Ибне Фадлан – Багдад хәлифе Әл-Мөкътәдирнең сәркатибе, аның тарафыннан Болгар җирләренә җибәрелгән илче.**





Фотоларның чыганагы: islam-today.ru

Бу илчелек Болгарга 922 елда килә. Һәм нәкъ менә әлеге ел болгарларның Ислам динен рәсми рәвештә кабул итү елы дип санала. Ибне Фадланның язулары буенча, болгарларның бер өлеше инде бу вакытта Ислам динендә булган.

X гасырда яшәгән гарәп географы һәм сәяхәтчесе Ибне Хәукаль Ән-Нәсиби болай дип билгеләп үткән: «Болгар күп биләмәләре булмаган кечкенә шәһәр. Ул көймәләр туктый торган урын булганга күрә дә танылган иде… әмма ул талауларга дучар булган».

Болгар дәүләтенең көчсезләнүе бу җирләргә рус походларының килүе белән бәйле була. Ә менә Зәкәрия бине Мөхәммәд Әл-Казвини (1283 елда вафат була) сүзләренчә, бер яктан, Болгар шәһәре зур дәүләтнең башкаласы булган, ә икенче яктан – әһәмиятле сәүдә шәһәре булып хезмәт иткән.

Болгар дәүләте халкының күбесе игенчелек белән шөгыльләнгән. X гасырның гарәп галиме, географ Ибне Рөстә болай дип язган: «Болгарлар – игенчелек белән шөгыльләнүче халык, алар: бодай, арпа, тары бөртекле ашлыгыннан икмәк әзерли».

Русь кнәзьлегендә иген уңмаган елларда болгарларның аларга икмәк җибәреп, җирле халыкны ачлыктан коткарып калганы билгеле.

Гарәп чыганаклары буенча X гасырда болгарларда ярым күчмә яшәү рәвеше өстенлек иткән. Кышкы вакытта алар өйләрдә яшәгән, ә язын һәм җәен кырларга чыгып, анда тирмәләрдә торган. Әмма бу терлек үрчетү өчен җәйге көтүлекләргә күчеп китү булмаган, ә кыр эшләре, игенчелек өчен күченү булган.

Инде XII гасырда танылган гарәп сәяхәтчесе Әбү Хәмид Әл-Гарнәти Әл-Әндалусинең язмаларында без болгарларның ярым күчмә яшәү рәвешеннән тулысынча утрак тормышка күчүләрен күрәбез.

*Утрак тормыш рәвешенә күчүдә зур рольне ислам дине уйнаган. Ибне Рөстә: «Аларның күпчелеге ислам динен тота, һәм аларның авылларында мәәзиннәре һәм имамнары белән мәчетләр һәм башлангыч белем бирү уку йортлары бар», – дип язган.*

Бу Болгарның Биләр, Сувар, Кашан, Казан, Җүкәтау, Кирмәнчек һәм башка шәһәрләренең көчле итеп үсүләренә китерә. X-XI гасырларда шәһәрләр төзелү Ислам мәдәниятының үсешенә илтә. Шул сәбәпле, утрак тормышта яшәүче татарларның дини җәмәгатьләре – мәхәлләләр формалаша башлый.

Ул вакытта төп төзү материалы агач була. Әбү Хәмид Әл-Гарнәти төзү эшләре һәм Болгар шәһәренең тышкы кыяфәте турында болай дип язган: «Болгар тулысынча нарат агачыннан төзелгән зур шәһәр, ә шәһәр диварлары имәннән төзелгән. Диварның теге ягында төрле халыклар яшәгән…»

Болгар җирләрендәге сәүдә турында ул болай дип язган: «Кешеләр бирегә Ислам илләрендә: Зәнҗәндә, Әбһәрдә, Тәбриздә һәм Исфәһәндә эшләнгән, утка чыдам булган кылычлар алып килә. Алар өчен түләү итеп кеш тиреләре ала һәм моннан зур табышка ия була».

Болгар турында мөһим мәгълүматларны Шиһабетдин Габдулла Якут Әл-Хәмәви (1229 елда вафат була) дә һәм танылган сәяхәтче Ибне Баттута (1304–1377) да калдырган.

Исмәгыйль Әбү Әл-Фида: «Болгарда бик яхшы мунчалар бар», – дип язган. Кайбер мәгълүматларга караганда, шәһәр нык итеп үсеш алган вакытта Болгар шәһәрендә 10 меңнән артык бина булган. Шәһәр сәяхәтчеләрне үзенең байлыгы һәм алга киткән сәүдәсе белән таң калдырган.

**Дамир Гайнетдинов язмасы,**
islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә



Фото: shutterstock.com

# БОЛГАР ӘМИРЕНЕҢ БАГДАД ХӘЛИФӘСЕНӘ ЯЗГАН ХАТЫ. БОЛГАРГА СӘЯХӘТ

**921 елның язында Багдадка Габдулла бине Башту җитәкчелегендәге илчелек килеп төшә. Ул ерак Болгардан Җәгъфәр бине Габдулла тарафыннан җибәрелгән була. Илче тарафыннан Габбасилар хәлифәсе Әл-Мөктъәдиргә тапшырылган хатында Җәгъфәр бине Габдулла аннан «Ислам диненең кануннарын аңлатучы, аның өчен мәчет төзеп бирүче, аның (хәлифәнең) Ислам диненә өндәвен халыкка җиткерү өчен аңа, Болгар патшасына, мөнбәр торгызучы кешеләр җибәрүен сораган, һәм ул, Болгар патшасы, дошман патшалардан саклансын өчен хәлифәдән кальга (крепость) төзеп бирүен үтенгән. Хәлифә исә, ул нәрсә сораса, шуңа ризалык бирә».**

921 елның 21 июнендә Багдадтан Идел Болгарына Сусан Әр-Расси һәм аның сәркатибе Әхмәд бине Фадлан җитәкчелегендә зур кәрван-илчелек чыгып китә. Юл Хамадан, Рей, Нишапур, Мәрв һәм Бохара аша Хәрәзмга кадәр дәвам итә. Аннан соң кәрван зур кыенлык белән ярымчүлле Устюрт яссылыгын кичеп үтә һәм Җаек елгасына килеп чыга. Сүзне Ибне Фадланга бирәбез:

*«Без болгарлар патшасыннан бер көн һәм бер төн ара ераклыгында булганда, безне каршылау өчен, ул үзенең хакимиятенә буйсынган дүрт патшаны, үзенең ир туганнарын һәм улларын җибәргән. Алар безне каршыладылар… Һәм без болгарлар патшасыннан ике фәрсах ара ераклыгында булганда, ул безне үзе каршылады, безне күргәч, атыннан төште, бөек һәм кодрәтле Аллаһыга табынып, рәхмәтләрен белдереп, йөзтүбән егылды. Аның җиң эчендә дирһәмнәр бар иде, һәм ул аларны безгә сипте. Ул безнең өчен чатырлар кордырды һәм безне аларда урнаштырды. Безнең аның янына килеп җитүебез – өч йөз унынчы ел мөхәррам аеның уникенче төне үткәч, якшәмбе көнне булды» (хәзерге календарь буенча 922 елның 17 маена туры килә).*

**Фаяз Хуҗин,**
археолог, тарих фәннәре докторы

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 04 (321) апрель, 2022 | Рамазан, 1443

# РАМАЗАННАН СОҢ БЕЗНЕҢ ХАЛӘТ



Фото: shutterstock.com

**Рамазан ае санаулы көннәр генә. Әле генә Рамазан аен түземсезлек белән көтеп алган, әкрен генә аңа ияләшә башлаган идек, инде соңгы ункөнлегенә дә аяк бастык. Рамазан аеның бер хикмәте бар: аны ныграк кадерләгән, олуглаган саен без үзебезгә күбрәк файда алабыз.**

Рамазан аенда Коръән укыган өчен күбрәк әҗер-саваплар бирелгәнен истә тотып, хәтем чыгарга тырышабыз, изге гамәлләр кылуларыбызны арттырырга, Аллаһыга якынаерга омтылып яшибез. Рамазан аеның иң зур хикмәте – тыелып торудыр. Әмма бу ризыктан, судан гына тыелып тору түгел. Без Рамазан аенда ялганнан, гайбәттән, кемгә дә булса кирәксез сүз әйтүдән, белмәгәнне сөйләүдән, хәтта башкалар турында начар уйларга бирелүдән дә тыелырга, булдыра алганча нәфесебезне тәрбияләргә, күңел халәтебезне үзгәртергә, калебебезне чистартырга тырышабыз. Ни өчен? Чөнки олуг айда Раббыбыз ризалыгы өчен дип, ихлас күңелләребездән тоткан уразаларыбызны әрәм итәсебез килми, бу изге гамәлебез ач торудан гына китәр дип бик нык куркабыз. Без Расүлебезнең Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителгән бер хәдистә: «Ялган сөйләүдән һәм ялган белән гамәл кылудан туктамаган кешенең, ураза тотам дип, ашау-эчүеннән калуына Аллаһы мохтаҗ түгел», – дигән сүзләрен яхшы беләбез (имам Әл-Бохари).

Димәк, әгәр без 30 көн дәвамында ялганнан, гайбәттән, начар сүзләрдән тыела алабыз, һәр көнне Коръәни Кәримне укырга вакыт табып, ай азагына хәтем кылабыз икән, Рамазаннан соң булган айларда моны эшләргә безгә нәрсә комачаулый соң? Ялкаулыкмы? Әллә нәфесме? Әллә үзебезнең кирелегебезме?

Чынлыкта, адәм баласы Аллаһы ризалыгы өчен дип ихлас күңелдән нинди дә булса олуг эшкә алынса, аны бөтен шартын китереп башкарып чыгарга сәләтле. Моңа безнең Аллаһының рәхмәте белән ай дәвамында уразалар тотып чыгуыбыз да, ифтар кылганнан соң ирләрнең мәчетләргә җыелып, ә хатын-кызларның өйләрендә укыган тәравих намазлары да, гадәттә, атналар буе кулга алырга вакыт тапмаган Коръәни Кәримебезне 30 көн эчендә хәтем кылуларыбыз да дәлил булып тора. Әйе, теләк булса, Аллаһының рәхмәте белән, без моны булдыра алабыз. Безне Раббыбыз рәхмәтеннән аермаса, саулык дигән олуг нигъмәт белән безне бүләкләсә, ураза тота да, төнге намазларны укый да, Коръәнне хәтем кыла да алабыз, чөнки Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә безне гыйбадәт кылыр өчен яратты. Ул болай дип әйтә:

> *«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым».*
>
> *«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56*

Ә инде бу гамәлләрне кылуны Рамазаннан соң да дәвам итүгә килгәндә, моның мөһимлеге хакында фикерләгәндә Расүлебезнең Гайшә радыяллаһу ганһәдән китерелгән күркәм хәдисен искә төшерик. Ул болай дип яңгырый: «Изге гамәлләрне тиешле дәрәҗәдә, ихластан башкарыгыз. Һәм истә тотыгыз: сез җәннәткә Аллаһының рәхмәте белән генә керәчәксез. Шуны истә тотыгыз: Аллаһы каршында иң сөекле гамәл – зур булмаса да, даими кылынган гамәл» (имам Әл-Бохари).

30 көн дәвамында Коръәнне укып чыгар өчен һәр көнне бер җөз Коръән укырга кирәк. Бу – 20 бит дигән сүз. Аллаһының рәхмәте белән Рамазан аенда без моны җиңеллек белән башкарабыз. Әмма, кызганычка, Рамазаннан соң Аллаһының сүзләре язылган кадерле Китабыбызга игътибарыбыз кими, чөнки без гамәлләребездә даимчылык кылырга тиешлегебезне дә һәм аз булса да, әмма даими кылынган гамәлнең Раббыбыз алдында кыйммәте зур икәнлеген дә тулысынча аңлап җиткермибез.

Әмма Рамазанда кылган изге гамәлләребез, биргән садакаларыбыз, төнге намазларыбыз, озаклап кылган догаларыбыз, динебез Исламны өйрәнү, китаплар уку, вәгазьләр, нәсыйхәтләр тыңлау, Коръәни Кәримне уку – Рамазаннан соң да дәвам итәргә тиеш. Әйе, кемгәдер һәр көнне көненә 20 бит уку авыр булырга мөмкин. Әмма: «Аз булса да, даими кылынган гамәл Аллаһыга сөеклерәк», – дигән хәдисне истә тотып, һәр кеше Коръән укуның күләмен дә үзенә үзе билгели ала. Мәсәлән, берәүгә көненә 20 бит Коръән уку кыен түгел һәм шул рәвешле ул ай саен Аллаһының Китабын хәтем кыла ала. Даими рәвештә укырга гына кирәк. Икенче берәү өчен көненә 10 бит яки 5 бит укырга җиңел, әмма без һич булмаса, көненә 2-3 бит булса да укысак та – бу да хәерле гамәл булыр. Вакыт үткән саен Коръән уку тизлегебез артып, Аллаһының рәхмәте белән, битләр санын тагы да арттырырбыз.

Психологлар, кеше берәр гадәткә ияләшсен һәм тормышына аны кертеп җибәрсен өчен 21 көн кирәк, дип әйтә. Бу тәртипне истә тотып, аңа тугрылык саклап, күпме кеше файдалы гадәтләрне тормышының нигезе итеп алды. Ә безгә олуг Китап – Коръәни Кәримне укуны гадәткә кертү өчен нәрсә комачау итә соң?! Ә бит Коръән – ул иң олуг зикер. Шушы зикердән үзебезне мәхрүм итмик. Аллаһының олуг нигъмәте булып бирелгән 24 сәгатьнең 24 минутын Коръәнгә багышлау һәркем өчен булдырырлык гамәл. Аңа салкын карамыйк, шуннан соң тормышыбызга вакытның бәрәкәте килгәнен һәм тагы да күбрәк эшләребезне башкарырга өлгергәнебезне аңларбыз. Үзегез дә сынап карый аласыз. Хәерле сәгатьтә!

**Айсылу Юлдашева**

# САФИЙӘ БИНТЕ ХӨЙӘЙ РАДЫЯЛЛАҺУ ГАНҺӘ

## ТУУЫ, НӘСЕЛЕ

Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә Мәдинәдә, якынча 610 нчы елда дөньяга килгән. Әтисе – Бәну Надир дип аталган яһүди кабиләсе башлыгы Хөйәй бине Әхтәб, Аллаһының Расүле белән килешүне бозганга күрә, Бәну Надир кабиләсе Мәдинә шәһәреннән куыла. Хөйәй бине Әхтәб Хайбәргә күченеп килә һәм шунда төпләнә. Монда да Аллаһының Расүленә каршы төрле мәкерле эшләрен кыла: Корәешлеләр һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә каршы булган башка кабиләләр арасында бер-берсенә карата ачу тарата.

## БАЛАЧАГЫ

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә һиҗрәт кылган вакытта Сафийә бинте Хөйәй әле яшь булган. Ләкин бик яшь булуына да карамастан, җәмгыятьтә барган вәзгыятьне аңларлык дәрәҗәдә булган. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән Расүл икәнлеген аңласалар да, яһүдиләр, шул исәптән, Сафийә бинте Хөйәйнең әтисе дә, Ислам диненә һәм Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә итагать күрсәтер урынына дошманлашып яшәүне кулайрак күргәннәр.

## ЯШЬЛЕГЕ

Балигълык яшенә җиткәч, Сафийә бинте Хөйәй гаскәри һәм шагыйрь Сәлләм бине Мишкамга кияүгә чыккан. Ләкин бу никах озын гомерле булмаган. Озак та үтми Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә бик бай һәм хөрмәтле булган яһүди Кинәнә бине Әл-Хакыйк Ән-Нударийга кияүгә чыккан. Кинәнәнең Хайбәрдә бик зур һәм ышанычлы ныгытмасы булган. Мөселманнар аны бик авырлык белән алганнар.

## ХАЙБӘР СУГЫШЫ

Хайбәр сугышында Гарәп ярымутравы мәкерле кабиләләрдән азат ителгән. Аларның байлыклары – ганимәт малы итеп, ә хатыннары әсирлеккә алынган. Алар арасында Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә дә булган.

## АЛЛАҺЫНЫҢ РАСҮЛЕ БЕЛӘН НИКАХЫ

Хайбәрне яулап алган көнне Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә Ислам динен кабул иткән. Бу вакыйга болай булган:

Сафийә бинте Хөйәйгә Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм сайлау мөмкинлеге биргән: ирекле булып, үз халкы янына кайтырга яки Ислам динен кабул итеп, аңа кияүгә чыгарга. Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу тәкъдименә болай дип җавап биргән: «Мин Аллаһы Тәгаләне һәм Аның Расүлен сайлыйм». Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аны әсирлектән азат иткән. Йолым аның мәһәре булган.

## ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ БЕЛӘН ТОРМЫШЫ

Никахлашканнан соң, Сафийә бинте Хөйәй Мәдинәгә күченеп, Аллаһы Расүленең күршесе – Харисә бине Ногъман радыяллаһу ганһенең өендә яши башлаган. Әнсарларның хатыннары Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһәнең матурлыгы турында күп ишеткән булганнар һәм моның дөресме-юкмы икәнен тикшерергә килгәннәр. Башка хатын-кызлар арасында Гайшә радыяллаһу ганһә дә булган. Аллаһының Расүле Гайшә радыяллаһу ганһәдән аның фикерен сораган. Гайшә җилкәсен тарткан да, көнчелектән ачуланып: «Минем фикеремчә, ул – яһүдә», – дип әйткән. Аллаһының Расүле: «Алай дип әйтмә, ул бит хәзер мөслимә. Ул Ислам динен кабул итте һәм үзенең иманын иң күркәм рәвештә исбатлады», – дип әйткән.

Әлеге хәлдән соң Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм йортына күчкән. Билгеле, Аллаһының Расүле Сафийәне бу өйдә кабул итмәгәннәрен аңлаган. Мөмкинлек булганда гел аны яклаган.

## САФИЙӘ БИНТЕ ХӨЙӘЙНЕҢ ДӘРӘҖӘСЕ

Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә күп дәрәҗәләргә ия булган. Тышкы матурлыгы белән беррәттән ул күркәм холкы, тәкъвалыгы, ярдәмчеллеге белән аерылып торган.

Риваятьләрдән күренгәнчә, Аллаһының Расүле авырый башлагач, хатыннары аның янына җыелган. Шул вакытта Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә: «Ий Аллаһының Расүле! Аллаһы белән ант итәм, мин синең урыныңда газапланырга теләр идем», – дип әйткән. Калган хатыннар бу хәлне күреп бер-берсенә күз кысышканнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм моны күреп: «Авызларыгызны чайкагыз», – дип әйткән. Алар Пәйгамбәребездән: «Аллаһының Расүле, ни өчен?» – дип сораганнар. Аллаһының Расүле: «Аллаһы белән ант итәм, ул ихлас әйтә», – дип әйткән.

## ВАФАТЫ

Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң шактый озак еллар яшәгән. Тәкъва һәм тугрылыклы хатын булганга, барлык гомерен Аллаһы Тәгаләгә итагать итү һәм гыйбадәткә багышлаган. Ул тугры хәлифәләр идарә иткән чорларда яшәп, бу чорларның зур үзгәрешләрен һәм авырлыкларын кичергән, мөселман өммәтенең күпчелек тарихи вакыйгаларында хәлиткеч роль уйнаган.

Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә Могавия идарә иткән чорда, һиҗри исәп буенча 50 нче еллар тирәсендә, 69 яшендә вафат булган.

Сафийә бинте Хөйәй радыяллаһу ганһә мөэминнәрнең аналары һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кызлары белән янәшә Бакыйгъ зиратында күмелгән. Аңа җеназа намазын күренекле сәхабәләр укыган.

Сәхифәне **Лилия Хәләфетдинова** әзерләде

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 04 (321) апрель, 2022 | Рамазан, 1443




# *Җиләкле тау сере*

*(Дәвамы. Башы алдагы саннарда)*

Бәкер санаториясендә ял итүчеләр дулкынына Тимерҗан белән Айбикә дә килеп кушылды. Республика халкының бәхетле кешеләре шушында җыйналып ял итә диярсең. Айбикә беренче көнне үк күрше бүлмәдә яшәүче Җәмилә һәм Рәсүл белән танышты. Лаеклы ялдагы укытучылар икәнен белеп чыкты. Икенче вакытта кергәндә, Коръән китабы укып утырганнарын күргәч, ишек төбендә тукталып калды.

– Безнең эш каты, – дип Җәмилә башын күтәрде. – Мәдрәсәдә укыйбыз, өй эше итеп бирелгән сүрәләр ятлыйбыз, – дигәч, Айбикә алар янында озак тоткарланмады.

Ул күрше бүлмәдән чыкканда, Тимерҗан да кичке намазга оеган иде. Айбикәгә шул мизгелдә иреннән уңайсыз булып китте, тизрәк намазлык өстенә басты. Ул сәҗдәгә киткәндә, үзенең Аллаһка тагын да якынайганын тойды. Күңелендә моңа кадәр булмаган яңа хис яралды. Ул күзен йомды һәм кулына Коръән тотып укыганын, Хаҗ кылырга барганын күрде.

...Айбикәнең күршедән ут капкандай чыгып, тиз генә намаз укырга керешкәне Тимерҗанга бераз сәеррәк тоелса да, хатынының үзе әйткәнен көтте.

– Ирле-хатынлы Коръән ятлаган кешеләр күргәнең бармы синең?– дип сорады Айбикә һәм ул аңа Җәмилә белән Рәсүл турында сөйләп бирде.

Күршеләр белән Тимерҗан да якынайды, буш вакытларын бергә уздыра башладылар. Дин һәм яшәеш – мәңгелек бәхәс кыры. Бу темага күпме генә сөйләшсәң дә, сүз бетәрлек түгел, һәр кешенең үз уе, үз фикере бар.

– Безнең буын кешеләре дин халык өчен агу дип тәрбияләнде. Ул заманда эшләгән укытучыларның хәзер мулла-абыстай булып йөрүен өнәмәүчеләр дә бар. Тик яшь саны өстәлә барган саен кешенең күңел халәте үзгәрә, Аллаһка якыная башлыйсың. Бу – котылгысыз, күпме генә каршы килергә тырышсаң да, үзеңнән-үзең кача алмыйсың, – ди Рәсүл...

Дөресе дә шулай бит дип уйлады Айбикә. Партия мәктәбендә белем алганда, имтихан алдыннан мәчеткә намаз укырга барганын укытучылар сизеп, үзенең чак кына куылмый калганын сөйләп күрсәтте.

– Ул чорда законы шундый иде, берәүне дә гаепли алмыйсың, – диеште Җәмилә белән Рәсүл, үзләренең дә атеизм фәне укытканын исләренә төшереп.

– Эчке дөньясын үзгәртергә Аллаһ бәндәгә сәбәбен бирә, – диде Җәмилә. – Бик каты авырдым мин, катлаулы операция кичердем. Исән калырмын, терелермен дип уйламадым. Хәл керә башлагач, үзеннән-үзе кулыма Коръән китабы тотып укыйсым килә башлады.

– Хатыным исән-сау терелсә, мәчеткә йөрер идем дип ният кылдым, – диде Рәсүл. – Алтмыш ике яшьтә өйрәнмәсәң, олыгая башлагач, бөтенләй хәтер бетәчәк. Аллага шөкер, икебез дә мәчеттә алдынгы укучылар саналабыз. Тигез вакытта, парлы чакта Хаҗ кылып та кайтасы килә...

Рәсүлнең Хаҗ сүзе Айбикәгә ток тоткандай тәэсир итте. Мизгел эчендә Тимерҗан белән карашлары очрашты. Бу гади караш кына түгел иде. Аның сез дә Хаҗ кылырга барыгыз дип Аллаһтан җибәрелгән билге икәнен икесе дә аңлады! Ир белән хатынның күңелдәге уйлары мизгел эчендә бер-берсенә күпер булып тоташты.

Үз бүлмәләренә кергәч, Тимерҗан:

– Иркәм, – дип, Айбикәне кулыннан тотып кочагына алды. – Рәхмәт сиңа, күңелемдә, җанымда ниләр кайнаганын аңлаганың өчен. Яратам, ихлас йөрәгем белән яратам сине, кадерлем...

Санаторийдан икесенең дә күңел халәте үзгәреп кайтты. Тимерҗан Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керде. Айбикә намазларын үз вакытында укый башлады. Теләк кенә көчле кирәк: җаен да табып, вакытын да көйләп була икән. Эш кабинетының эчке бүлмәсенә намазлык алып куйды. Айбикәнең Аллаһка ышануы үзе белән бергә тугандыр. Нинди мәсьәлә хәл итәсе булса да, ул аның чишелешен намаз укыган вакытта таба башлады. Уйлар, яңа фикерләр намазлык өстенә баскач, дулкын булып агыла. Ходай биргән көннең бер генә сәгате дә бушка узмый, авыл халкына игелекле хезмәттә үтүенә сөенеп-куанып бетә алмый. Тик башына яулык кияргә генә читенсенә. Үз-үзен пенсиягә чыгарга күп калмады дип юата.

*(Дәвамы киләсе саннарда)*

## Ий Аллам!

*Олуг булган Рәхмәтеңнең*
*Чиге юктыр, бер Аллам!*
*Күңелләргә тәүфыйк салып,*
*Ярлыкачы, ий Аллам!*

*Илләр-көннәр тыныч булсын,*
*Имин булсын дөньялар.*
*Матурлыкны күреп үссен*
*Безнең газиз балалар.*

*Синең бөек нигъмәтләрең*
*Чиксез бит ул, күп бит ул.*
*Күңел күзе сукыр булса,*
*Маңгай күзе юк бит ул!*

*Раббым Аллам догам илә*
*Мөрәҗәгатем Сиңа*
*Сакла, якла, ярдәм итче*
*Безгә - мәхлүкъларыңа.*

*Сине танып, янып яшәү*
*Һәркемгә дә бирелми.*
*Олуг нигъмәт чаткылары*
*Күңелләрдә сүрелми.*

*Раббым, насыйп итче безгә*
*Шул рәвешле яшәргә.*
*Соңгы сулышларга кадәр*
*Раббым, диеп дәшәргә.*

**Айсылу Газизова-Юлдашева**

## ХӨРМӘТЛЕ РАДИОТЫҢЛАУЧЫЛАР!

«Азан» радиосын **azan.fm** сайтында яки **«АЗАН» РАДИОСЫ** рәсми кушымталары аша тыңлагыз. Моның өчен түбәндәге QR-код аша үтегез яки App Store (iPhone өчен) һәм Google Play Market (Android өчен) платформаларыннан «Азан радиосы» кушымтасын йөкләп алыгыз.

**ANDROID ӨЧЕН:** **IPHONE ӨЧЕН:**

| САЙТ: | ВКОНТАКТЕ: | ТЕЛЕГРАМ-КАНАЛ: | ПОЧТА: | ТЕЛЕФОН: |
|---|---|---|---|---|
| azan.fm | azanfm | azanfm | radio@azan.fm | 8 (843) 598-09-43 |

### ДҮШӘМБЕ, СИШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ

| | |
|---|---|
| **0:00** | Коръәни Кәрим 0+ |
| **6:05** | Коръән тәфсире 12+ |
| **6:25** | Көндәлек догалар 6+ |
| **6:30** | Тынычлык тәгълимате 12+ |
| **7:05** | Таян Аллаһка 6+ |
| **7:20** | Хәзрәткә сорау 12+ |
| **7:30** | Иман тәме 12+ |
| **7:50** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **7:55** | Гыйбрәтле кыйссалар 6+ |
| **8:05** | Бәхет тулы йорт 12+ |
| **8:30** | Күңелдән күңелгә 12+ |
| **8:50** | Шәхесләргә шәрехләр 6+ |
| **9:00** | Рухи хәзинә 6+ |
| **9:15** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **9:30** | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+ |
| **9:40** | Әбү Хәнифә (р.г.) 12+ |
| **10:40** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **10:45** | Көндәлек догалар 6+ |
| **10:50** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **11:00** | 40 хәдис 6+ |
| **11:20** | Аллаһның 99 исеме 6+ |
| **11:30** | Мәчетләребез тарихы 6+ |
| **11:40** | 101 вәгазь 12+ |
| **12:00** | Өйләгә азан 0+ |
| **12:10** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **12:25** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **12:30** | Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә 12+ |
| **14:00** | Гыйбадәттә сәгадәт 12+ |
| **14:10** | Әхлак баскычлары 6+ |
| **14:30** | Пәйгамбәрләр тарихы 12+ |
| **14:45** | Сөннәт юлы 12+ |
| **15:05** | Коръән тәфсире 12+ |
| **15:25** | Көндәлек догалар 6+ |
| **15:45** | Бәхет тулы йорт 12+ |
| **16:05** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **16:10** | Гыйбрәтле кыйссалар 6+ |
| **16:20** | 101 вәгазь 12+ |
| **16:40** | Күңелдән күңелгә 12+ |
| **17:00** | Шәхесләргә шәрехләр 6+ |
| **17:10** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **17:30** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **17:40** | 40 хәдис 6+ |
| **19:30** | Әдәбият күрке әдәп 6+ |
| **19:45** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **20:00** | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+ |
| **20:20** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **20:30** | Нәниләргә нәсыйхәт 6+ |
| **20:35** | Пәйгамбәрләр тарихы 12+ |
| **20:50** | Көндәлек догалар 6+ |
| **21:10** | Мәчетләребез тарихы 6+ |
| **21:30** | Әбү Хәнифә (р.г.) 12+ |
| **21:50** | Хәзрәткә сорау 12+ |
| **22:00** | Гыйбадәттә сәгадәт 12+ |
| **22:10** | Әхлак баскычлары 6+ |
| **22:37** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **22:45** | Аллаһның 99 исеме 6+ |
| **23:00** | Коръәни Кәрим 0+ |

### ҖОМГА

| | |
|---|---|
| **0:00** | Коръәни Кәрим 0+ |
| **6:00** | Җомга тәбриге 12+ |
| **6:05** | Коръән тәфсире 12+ |
| **6:25** | Көндәлек догалар 6+ |
| **6:30** | Тынычлык тәгълимате 12+ |
| **7:05** | Таян Аллаһка 6+ |
| **7:20** | Хәзрәткә сорау 12+ |
| **7:30** | Иман тәме 12+ |
| **7:50** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **7:55** | Гыйбрәтле кыйссалар 6+ |
| **8:05** | Бәхет тулы йорт 12+ |
| **8:25** | Җомга тәбриге 12+ |
| **8:30** | Күңелдән күңелгә 12+ |
| **8:50** | Шәхесләргә шәрехләр 6+ |
| **9:00** | Рухи хәзинә 6+ |
| **9:15** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **9:30** | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+ |
| **9:40** | Әбү Хәнифә (р.г.) 12+ |
| **10:00** | Җомга тәбриге 12+ |
| **10:40** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **10:45** | Көндәлек догалар 6+ |
| **10:50** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **11:00** | 40 хәдис 6+ |
| **11:20** | Аллаһның 99 исеме 6+ |
| **11:30** | Мәчетләребез тарихы 6+ |
| **11:40** | 101 вәгазь 12+ |
| **12:00** | Өйләгә азан 0+ |
| **12:10** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **12:25** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **12:30** | Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә 12+ |
| **14:00** | Гыйбадәттә сәгадәт 12+ |
| **14:10** | Әхлак баскычлары 6+ |
| **14:30** | Пәйгамбәрләр тарихы 12+ |
| **14:45** | Сөннәт юлы 12+ |
| **15:00** | Җомга тәбриге 12+ |
| **15:05** | Коръән тәфсире 12+ |
| **15:25** | Көндәлек догалар 6+ |
| **15:45** | Бәхет тулы йорт 12+ |
| **16:05** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **16:10** | Гыйбрәтле кыйссалар 6+ |
| **16:20** | 101 вәгазь 12+ |
| **16:40** | Күңелдән күңелгә 12+ |
| **17:00** | Шәхесләргә шәрехләр 6+ |
| **17:10** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **17:30** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **17:40** | 40 хәдис 6+ |
| **19:30** | Әдәбият күрке әдәп 12+ |
| **19:45** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **20:00** | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+ |
| **20:20** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **20:30** | Нәниләргә нәсыйхәт 6+ |
| **20:35** | Пәйгамбәрләр тарихы 12+ |
| **20:50** | Көндәлек догалар 6+ |
| **21:10** | Мәчетләребез тарихы 6+ |
| **21:30** | Әбү Хәнифә (р.г.) 12+ |
| **21:50** | Хәзрәткә сорау 12+ |
| **22:00** | Гыйбадәттә сәгадәт 12+ |
| **22:10** | Әхлак баскычлары 6+ |
| **22:37** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **22:45** | Аллаһның 99 исеме 6+ |
| **23:00** | Коръәни Кәрим 0+ |

### ШИМБӘ, ЯКШӘМБЕ

| | |
|---|---|
| **0:00** | Коръәни Кәрим 0+ |
| **6:05** | Коръән тәфсире 12+ |
| **6:25** | Көндәлек догалар 6+ |
| **6:30** | Тынычлык тәгълимате 12+ |
| **7:05** | Таян Аллаһка 6+ |
| **7:20** | Хәзрәткә сорау 12+ |
| **7:30** | Иман тәме 12+ |
| **7:50** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **7:55** | Гыйбрәтле кыйссалар 6+ |
| **8:05** | Бәхет тулы йорт 12+ |
| **8:30** | Күңелдән күңелгә 12+ |
| **8:50** | Шәхесләргә шәрехләр 6+ |
| **9:00** | Рухи хәзинә 6+ |
| **9:15** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **9:30** | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+ |
| **9:40** | Әбү Хәнифә (р.г.) 12+ |
| **10:40** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **10:45** | Көндәлек догалар 6+ |
| **10:50** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **11:00** | 40 хәдис 6+ |
| **11:20** | Аллаһның 99 исеме 6+ |
| **11:30** | Мәчетләребез тарихы 6+ |
| **11:40** | 101 вәгазь 12+ |
| **12:00** | Өйләгә азан 0+ |
| **12:10** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **12:25** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **12:30** | Кәлам Шәриф. Тәрҗемә 12+ |
| **14:00** | Гыйбадәттә сәгадәт 6+ |
| **14:10** | Әхлак баскычлары 6+ |
| **14:30** | Пәйгамбәрләр тарихы 12+ |
| **14:45** | Сөннәт юлы 12+ |
| **15:05** | Коръән тәфсире 12+ |
| **15:25** | Көндәлек догалар 6+ |
| **15:45** | Бәхет тулы йорт 12+ |
| **16:05** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **16:10** | Гыйбрәтле кыйссалар 6+ |
| **16:20** | 101 вәгазь 12+ |
| **16:40** | Күңелдән күңелгә 12+ |
| **17:00** | Шәхесләргә шәрехләр 6+ |
| **17:10** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **17:30** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **17:40** | 40 хәдис 6+ |
| **19:30** | Әдәбият күрке әдәп 12+ |
| **19:45** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **20:00** | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+ |
| **20:20** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **20:30** | Нәниләргә нәсыйхәт 6+ |
| **20:35** | Пәйгамбәрләр тарихы 12+ |
| **20:50** | Көндәлек догалар 6+ |
| **21:10** | Мәчетләребез тарихы 6+ |
| **21:30** | Әбү Хәнифә (р.г.) 12+ |
| **21:50** | Хәзрәткә сорау 12+ |
| **22:00** | Гыйбадәттә сәгадәт 12+ |
| **22.10** | Әхлак баскычлары 6+ |
| **22:37** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **22:45** | Аллаһның 99 исеме 6+ |
| **23:00** | Коръәни Кәрим 0+ |

*** Тапшырулар арасында эфирда кыска хәдисләр, нәшидләр һәм мөнәҗәтләр яңгырый**

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**

Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН;**

«Хозур» нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН;**

ТР МДНнең Шәригать бүлеге житәкчесе **Булат МӨБАРӘКОВ;**

Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**

ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы **Габдулла ӘДҺӘМОВ**

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррир: **Юлдашева А. И.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Шәйхетдинов А. Х.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**НӘШИР:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт).
Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.

Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.

Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә. Заказ №2728.
График буенча – 22 нче апрель 21.00, гамәлдә – 21.00 сәгатьтә кул куелды.

Газетага ярты елга язылу бәясе – 140, 40 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 26 нчы апрель көнне таратыла.

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

## МАЙ 2022 / КАЗАН

| Көн | Көн исеме | ИРТӘНГЕ НАМАЗ | | Кояш чыга | ЗӘВӘЛ | ӨЙЛӘ НАМАЗЫ | ИКЕНДЕ НАМАЗЫ | АХШАМ НАМАЗЫ / ИФТАР | ЯСТУ НАМАЗЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | | |
| 01 | Якш | 00:43 | 02:30 | 04:00 | 11:40 | 12:00 | 16:52 | 19:21 | 21:46 |
| 02 | Дүш | 00:35 | 02:28 | 03:58 | 11:40 | 12:00 | 16:53 | 19:23 | 21:50 |
| 03 | Сиш | 00:26 | 02:26 | 03:56 | 11:40 | 12:00 | 16:54 | 19:25 | 21:54 |
| 04 | Чәрш | 00:14 | 02:24 | 03:54 | 11:40 | 12:00 | 16:56 | 19:27 | 21:59 |
| 05 | Пәнҗ | 23:55 | 02:22 | 03:52 | 11:40 | 12:00 | 16:57 | 19:29 | 20:59 |
| 06 | Җом | 01:49 | 02:19 | 03:49 | 11:40 | 12:00 | 16:58 | 19:31 | 21:01 |
| 07 | Шим | 01:47 | 02:17 | 03:47 | 11:40 | 12:00 | 16:59 | 19:33 | 21:03 |
| 08 | Якш | 01:45 | 02:15 | 03:45 | 11:40 | 12:00 | 17:00 | 19:35 | 21:05 |
| 09 | Дүш | 01:43 | 02:13 | 03:43 | 11:39 | 12:00 | 17:01 | 19:37 | 21:07 |
| 10 | Сиш | 01:41 | 02:11 | 03:41 | 11:39 | 12:00 | 17:03 | 19:39 | 21:09 |
| 11 | Чәрш | 01:39 | 02:09 | 03:39 | 11:39 | 12:00 | 17:04 | 19:41 | 21:11 |
| 12 | Пәнҗ | 01:37 | 02:07 | 03:37 | 11:39 | 12:00 | 17:05 | 19:43 | 21:13 |
| 13 | Җом | 01:35 | 02:05 | 03:35 | 11:39 | 12:00 | 17:06 | 19:45 | 21:15 |
| 14 | Шим | 01:33 | 02:03 | 03:33 | 11:39 | 12:00 | 17:07 | 19:47 | 21:17 |
| 15 | Якш | 01:32 | 02:02 | 03:32 | 11:39 | 12:00 | 17:08 | 19:48 | 21:18 |
| 16 | Дүш | 01:30 | 02:00 | 03:30 | 11:39 | 12:00 | 17:09 | 19:50 | 21:20 |
| 17 | Сиш | 01:28 | 01:58 | 03:28 | 11:39 | 12:00 | 17:10 | 19:52 | 21:22 |
| 18 | Чәрш | 01:26 | 01:56 | 03:26 | 11:39 | 12:00 | 17:11 | 19:54 | 21:24 |
| 19 | Пәнҗ | 01:25 | 01:55 | 03:25 | 11:39 | 12:00 | 17:12 | 19:56 | 21:26 |
| 20 | Җом | 01:23 | 01:53 | 03:23 | 11:40 | 12:00 | 17:13 | 19:57 | 21:27 |
| 21 | Шим | 01:21 | 01:51 | 03:21 | 11:40 | 12:00 | 17:14 | 19:59 | 21:29 |
| 22 | Якш | 01:20 | 01:50 | 03:20 | 11:40 | 12:00 | 17:15 | 20:01 | 21:31 |
| 23 | Дүш | 01:18 | 01:48 | 03:18 | 11:40 | 12:00 | 17:16 | 20:02 | 21:32 |
| 24 | Сиш | 01:17 | 01:47 | 03:17 | 11:40 | 12:00 | 17:17 | 20:04 | 21:34 |
| 25 | Чәрш | 01:15 | 01:45 | 03:15 | 11:40 | 12:00 | 17:18 | 20:06 | 21:36 |
| 26 | Пәнҗ | 01:14 | 01:44 | 03:14 | 11:40 | 12:00 | 17:19 | 20:07 | 21:37 |
| 27 | Җом | 01:13 | 01:43 | 03:13 | 11:40 | 12:00 | 17:20 | 20:09 | 21:39 |
| 28 | Шим | 01:11 | 01:41 | 03:11 | 11:40 | 12:00 | 17:20 | 20:10 | 21:40 |
| 29 | Якш | 01:10 | 01:40 | 03:10 | 11:40 | 12:00 | 17:21 | 20:12 | 21:42 |
| 30 | Дүш | 01:09 | 01:39 | 03:09 | 11:41 | 12:00 | 17:22 | 20:13 | 21:43 |
| 31 | Сиш | 01:08 | 01:38 | 03:08 | 11:41 | 12:00 | 17:23 | 20:15 | 21:45 |